**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 4 август | № 565

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче, 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче, 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче, 2013 ел, 11 май, 313 нче, 2013 ел, 29 июнь, 455 нче, 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче, 2014 ел, 28 май, 362 нче, 2014 ел, 27 июнь, 443 нче, 2014 ел, 25 август, 613 нче, 2014 ел, 06 октябрь, 726 нчы, 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче, 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемендә һәм текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмә исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

1.1, 1.3 пунктларга «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карамагындагы дәүләт медицина оешмаларында һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрдә хезмәткә түләү фонды казна учреждениеләре хезмәткәрләре хезмәтенә түләүгә каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет йөкләмәләре лимитлары күләменнән, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карамагындагы дәүләт медицина оешмаларына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләргә дәүләт биреме нигезендә алар күрсәткән дәүләт хезмәтләре (башкарган эшләр) белән бәйле норматив чыгымнарны кире кайтаруга бирелгән субсидияләр күләменнән, медицина хезмәтләре күрсәтүгә чыгымнарны кире кайтаруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләве территориаль фонды бюджеты акчасы күләменнән чыгып календарь елга формалаша.»;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 8.8 пункт өстәргә:

«8.8. Югары технологик медицина ярдәме һәм катаракта белән авыручыларга «эластик интраокуляр линзалар имплантациясе белән катарактаны микроинвазив энергетик хирургия» операциясен кулланып медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмаларында медицина ярдәменең әлеге төрләрен күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина персоналына (операция ясаучы бригада составына, врачларга һәм авыруларга турыдан-туры хезмәт күрсәтүче урта медицина персоналына) стимуллаштыручы характердагы түләүләр фонды булдырыла.

Стимуллаштыручы характердагы түләүләр фонды тиешле финанс елына югары технологик медицина ярдәме, катаракта белән авыручыларга «эластик интраокуляр линзалар имплантациясе белән катарактаны микроинвазив энергетик хирургия» операциясен кулланып медицина ярдәме күрсәтүгә планлаштырылган биремне финанс ягыннан тәэмин итү күләме кысаларында формалаша һәм күрсәтелгән күләмнең 11 процентыннан артып китә алмый.»;

әлеге Нигезләмәгә 1 – 14 нче кушымталарның санлы исемнәрендә, 2 нче кушымтада астөшермәдә, 4 нче кушымтаның исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмалары эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

Нигезләмәнең исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына

һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

1.1, 2.1 пунктларда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның беренче абзацында «дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

3.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» дәүләт автоном учреждениесендә эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен өстәмә түләүнең тәкъдим ителә торган күләме 100 процент тәшкил итә.»;

4.2 пунктта «дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче һәм 2 нче кушымталарының санлы исемнәрендә, 1 нче кушымтаның исемендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның таблицасында:

13 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына» сүзләреннән соң «, һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы аерым типик булмаган учреждениеләрнең» сүзләрен өстәргә;

таблицага түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «20. | «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчер үзәге» дәүләт автоном учреждениесендә эш | җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләр | 100». |

2. Әлеге карарның көче 2015 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә, әлеге карарның 1 пунктының сигезенче – унынчы абзацларыннан тыш, аларның көче 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков